| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОШУГУРОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ШӨГЕР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2022 елның 02 феврале № 2

«Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында

«Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 06 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Иске Шөгер авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

143 пунктның 1 пунктчасында «терлекчелек продуктлары» сүзләрен «терлектән килеп чыккан продукция» сүзләренә алыштырырга.

(2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә).

2. Әлеге карарны Лениногорск районы, Иске Шөгер - җирле үзидарә бинасы, Совет урамы, 1 нче йорт, Совет урамы, 3 нче йорт буенча урнашкан балалар бакчасы бинасында, М. Җәлил урамы, 33 нче йорт, Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур., 1/а адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы
Совет рәисе Л.М.Шиһапова